КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 13 июль г.Казань № б-1561

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә Педагог һәм остаз елын үткәрү турында» 2022 елның 27 июнендәге 401 номерлы Указының 2 пунктындагы «б» пунктчасын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 23 ноябрь, б-2577 нче боерыгын үтәү йөзеннән:

1. Бу боерыкка теркәлгән 2023 елның икенче яртыеллыгына Татарстан Республикасында Педагог һәм остаз елын үткәрү буенча төп чаралар планын (алга таба – План) расларга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына муниципаль берәмлекләрдә План чараларын үткәрү эшен оештыруны тәкъдим итәргә.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасында Педагог һәм остаз елын үткәрүне яктыртуны тәэмин итәргә.

4. План чараларын финанс белән тәэмин итү 2023 елга Татарстан Республикасы бюджетында республика башкарма хакимият органнарына каралган ассигнованиеләр чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 13 июль, б-1561 нче
боерыгы белән расланды

# 2023 елның икенче яртыеллыгына
# Татарстан Республикасында Педагог һәм остаз елын үткәрү буенча
# төп чаралар планы

| Т/с | Чараның исеме | Үткәрү срогы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | 2023 елда Россия Федерациясендә Педагог һәм остаз елын үткәрү буенча төп чаралар планын гамәлгә ашыруда катнашу | икенче яртыеллык дәвамында | ТР МһФМ[1], ТР МБ ҖҮО (килешү буенча) |
| 2. | Россия Федерациясендә К.Д.Ушинский тууының 200 еллыгы уңаеннан төп чараларны гамәлгә ашыруда катнашу | икенче яртыеллык дәвамында | ТР МһФМ, ТР МБ ҖҮО (килешү буенча) |
| | I. Тантаналы чаралар | | |
| 1.1. | Педагог һәм остаз елына багышланган мәгариф атнасы, түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән хезмәткәрләренең август конференциясе;<br>секцияләр һәм дискуссия мәйданчыклары;<br>яшь педагогларны «Укытучы» һөнәренә багышлау;<br>конференция темасы һәм Мәгариф атнасы буенча күргәзмәләр;<br>Татарстан Республикасында остазлык институтын үстерү һәм популярлаштыру буенча чаралар циклы (конференцияләр, түгәрәк өстәлләр, мастер-класслар, очрашулар һ.б.) | август | ТР МһФМ |
| 1.2. | Зур укытучылар атнасы кысаларында Укытучылар көне | октябрь | ТР МһФМ |
| 1.3. | Зур укытучылар атнасы кысаларында, шул исәптән Татарстан Республикасында остазлык институтын үстерү һәм популярлаштыру буенча (конференцияләр, | октябрь | ТР МһФМ |

[1] Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге – 5 нче биттә.

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | түгәрәк өстәлләр, мастер-класслар, очрашулар һ.б.) чаралар циклы | | |
| 1.4. | Татарстан Республикасында Педагог һәм остаз елын ябуга багышланган тантаналы чара | декабрь | ТР МһФМ |
| II. Мәгълүматның ачык булуы | | | |
| 2.1. | «Укытучы булу – сәләт ул» яки «Укытучы һөнәре турында» телерадиотапшырулар циклын, Россия1, ТНВ, Эфир, Шаян ТВ һ.б. каналларындагы «Манзара», «Доброе утро», «Здравствуйте», «Заман көзгесе», «Җиде көн», «Актуаль сөйләшү» программаларында танылган педагоглар, остазлар, яшь укытучылар, һөнәри конкурсларда (мәсәлән, «Ел укытучысы», «Ел тәрбиячесе», «Иң яхшы туган тел һәм әдәбият укытучысы» һ.б.) җиңүчеләр белән очрашулар үткәрү | ай саен | «Татмедиа» РА, ТР МһФМ |
| 2.2. | Һөнәри конкурсларда җиңүчеләрнең, остазларның фотосурәтләре (сурәтләре) белән баннерлар (билбордлар), шул исәптән рәсми сайтларда урнаштыру | икенче яртыеллык дәвамында | ТР МһФМ, ТР МБ ҖҮО (килешү буенча) |
| 2.3. | Социаль челтәрләрдә, массакүләм мәгълүмат чараларында, «Мәгариф», «Гаилә һәм мәктәп» һ.б.ш. журналларда иң яхшы педагоглар һәм остазлар турында мәкаләләр циклы | икенче яртыеллык дәвамында | «Татмедиа» РА, ТР МһФМ |
| III. Гомумсистема чаралары | | | |
| 3.1. | Татарстан Республикасы мәгариф музеен булдыру | икенче яртыеллык дәвамында | ТР МһФМ, КФУ (килешү буенча), ТР МБ ҖҮО (килешү буенча) |
| 3.2. | Татарстан Республикасында Укытучы һәйкәлен урнаштыру һәм скверын булдыру | икенче яртыеллык дәвамында | ТР МһФМ, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча) |
| 3.3. | Татарстан Республикасының мәгариф системасы турында «Татарстан мәгарифе: 100 ел төзү һәм үстерү» китап басмасы | икенче яртыеллык дәвамында | ТР МһФМ, ТР МБ ҖҮО (килешү буенча) |
| 3.4. | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ведомство бүләкләре исемлеген арттыру («Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы», «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклаган һәм үстергән өчен», «Яшь мөгаллим» күкрәк билгеләре) | икенче яртыеллык дәвамында | ТР МһФМ |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 3.5. | Күренекле татар мәгърифәтчеләренең педагогик эшчәнлегенә багышланган республика форумы (Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Р.Фәхреддин) | икенче яртыеллык | ТР МһФМ, ТР МҮИ, КФУ (килешү буенча) |
| 3.6. | А.С.Пушкин исемендәге мәктәпләрнең педагогик хезмәткәрләре һәм идарә кадрларының халыкара форумы | сентябрь | ТР МһФМ, ТР МҮИ, КФУ (килешү буенча) |
| 3.7. | «Мәгариф: яшьләр карашы» бөтенроссия яшьләр психологик-педагогик форумы | октябрь | КФУ (килешү буенча) |
| 3.8. | Мәктәп укытучыларының XIII Халыкара фестивале | август | ТР МһФМ, КФУ АИ (килешү буенча), ТР МБ ҖҮО (килешү буенча) |
| 3.9. | «Буыннар диалогы» Татарстан Республикасы педагоглар династияләре фестивале | октябрь | ТР МһФМ, ТР МБ ҖҮО (килешү буенча) |
| 3.10. | Рус, татар теле һәм чит телләр укытучылары өчен «Тел трендлары һәм методик инновацияләр» республика лингвометодик фестивале | ноябрь | КФУ (килешү буенча), ТР МһФМ |
| 3.11. | IX Халыкара Мәхмүтов укулары | сентябрь | КФУ АИ (килешү буенча) |
| 3.12. | I Республика Вәгыйзов укулары (Сәләй Гатат улы Вәгыйзов – татар телендә «Әлифба» дәреслеге авторы) | октябрь | ТР МһФМ, ТР МБ ҖҮО (килешү буенча), АПК |
| 3.13. | Төрле елларда балалар йортында эшләгән күренекле педагог-тәрбиячеләргә һәм остазларга багышланган «Туган йөрәкләр йорты» әдәби-музыкаль композициясе | октябрь | ТР МһФМ, ЛБЙ |
| 3.14. | Халыкара катнашында «Мәгарифтә остазлык: хәзерге заман теориясе һәм инновацияле тәҗрибә» V Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе | октябрь | ТР МҮИ |
| 3.15. | «Белем бирү эшчәнлеге контекстында мәдәниятләр диалогы» бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе | декабрь | ЧДПУ (килешү буенча) |
| 3.16. | Ветеран педагогларны чакырып, «Искиткеч кешеләр тормышы» сериясеннән тематик очрашулар циклы | икенче яртыеллык дәвамында | ТР МһФМ, ТКБЙ |
| 3.17. | Ата-аналар җәмәгатьчелеге белән чаралар циклы | икенче яртыеллык дәвамында | ТР МһФМ, ТР МБ ҖҮО (килешү буенча), МО (килешү буенча) |
| 3.18. | Сыйныф җитәкчеләре, җәмәгать тәрбиячеләре өчен тематик семинарлар, түгәрәк өстәлләр, дискуссияләр циклы | икенче яртыеллык дәвамында | ТР МһФМ, ТР МБ ҖҮО (килешү буенча), МО (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 3.19. | Түбәндәге чаралар циклы:<br>мәгарифне цифрлаштыру;<br>укучыларда функциональ грамоталылыкны формалаштыру һәм үстерү;<br>яңа шартларда остазлык эшчәнлеген камилләштерү;<br>белем бирү барышын психологик тәэмин итү;<br>Татарстан Республикасында остазлык институтын үстерү һәм популярлаштыру һ.б. | икенче яртыеллык дәвамында | ТР МһФМ, ТР МБ ҖҮО (килешү буенча), МО (килешү буенча) |
| 3.20. | «Без срока давности» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында укытучыларның (педагоглар) һәм остазларның батырлыгын яктырту буенча чаралар циклы | икенче яртыеллык дәвамында | ТР МһФМ, ТР МБ ҖҮО (килешү буенча), МО (килешү буенча) |
| 3.21. | «Җир йөзендә әлеге һөнәрдән башка гүзәл һөнәр юк», «Укытучының бөеклеген данлыйбыз» темасына сыйныф сәгатьләре, әңгәмәләр | икенче яртыеллык дәвамында | ТР МһФМ, МО (килешү буенча) |
| | IV. Конкурслар | | |
| 4.1. | Татарстан Республикасы методистларына һәм педагогик хезмәткәрләренә грант ярдәмен алуга республика конкурслары | икенче яртыеллык | ТР МһФМ |
| 4.2. | «Мәгарифтә инновацияләр» һәм «Перспектива» номинацияләрендә «Татарстан Республикасы өчен илле иң яхшы инновацияле идея» республика конкурсы | икенче яртыеллык | ТР МһФМ, ТР МҮИ, ТР МБ (килешү буенча) |
| 4.3. | М.И.Мәхмүтов исемендәге Татарстан Республикасы дәүләт премиясен алуга республика конкурсы | икенче яртыеллык | ТР МһФМ, ТР МҮИ, ЮББ МО (килешү буенча), ТР МБ ҖҮО (килешү буенча) |
| 4.4. | Каюм Насыйри исемендәге республика премиясен алуга конкурс | икенче яртыеллык | ТР МһФМ |
| 4.5. | Ризаэддин Фәхреддин исемендәге республика премиясен алуга конкурс | икенче яртыеллык | ТР МһФМ |
| 4.6. | Рус телендә сөйләшүче тәрбиячеләрнең «Мин татарча сөйләшәм һәм эшлим – 2023» VII Республика һөнәри конкурсы | икенче яртыеллык | ТР МһФМ, АПК |
| | V. Күргәзмәләр, акцияләр | | |
| 5.1. | «Борынгы философларның педагогик идеяләре» тамаша күргәзмәсе | икенче яртыеллык | ТР МһФМ, ТР МБ ҖҮО (килешү буенча), МО (килешү буенча) |
| 5.2. | «Сурәтләрдә педагоглар, остазлар» тамаша күргәзмәсе | икенче яртыеллык | ТР МһФМ, ТР МБ ҖҮО (килешү буенча), МО (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 5.3. | «Яраткан укытучыга, остазга чәчәк бәйләме» котлау күргәзмәсе | икенче яртыеллык | ТР МhФМ, ТР МБ ҖҮО (килешү буенча), МО (килешү буенча) |
| 5.4. | «Исәнме, мәктәп!» видеосәлам акциясе | икенче яртыеллык | ТР МhФМ, ТР МБ ҖҮО (килешү буенча), МО (килешү буенча) |
| 5.5. | «Укытучы көне – искиткеч матур бәйрәм» котлау күргәзмәсе | икенче яртыеллык | ТР МhФМ, ТР МБ ҖҮО (килешү буенча), МО (килешү буенча) |
| 5.6. | «Чын күңелдән» акциясе (педагогик хезмәт ветераннарына бүләкләр әзерләү һәм тапшыру) | икенче яртыеллык | ТР МhФМ, ТР МБ ҖҮО (килешү буенча), МО (килешү буенча) |
| 5.7. | «Татарстанның иң иске уку йортлары буйлап» сәяхәт күргәзмәсе | икенче яртыеллык | ТР МhФМ, ТР МБ ҖҮО (килешү буенча), МО (килешү буенча) |
| 5.8. | «Минем яраткан укытучым, остазым» фотоархивын булдыру | икенче яртыеллык | ТР МhФМ, ТР МБ ҖҮО (килешү буенча), МО (килешү буенча) |
| VI. Чараларны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | | | |
| 6.1. | Педагогик сыйныфларны, абитуриентларны, ата-аналарны кертеп, укучылар арасында рәсми аккаунтларга (электрон һәм басма ММЧндагы, ВКонтакте, Telegram, Одноклассники социаль челтәрләрендәге даими рубрикаларга) язылучылар санын 2,5 – 3 тапкырга арттыру | декабрь | ТР МhФМ |
| 6.2. | Абитуриентлар тарафыннан югары уку йортларының һәм педагогика көллиятләренең педагогика юнәлешләренә тапшырылган гаризалар санын үткән ел белән чагыштырганда 15 процентка арттыру | декабрь | ТР МhФМ |
| 6.3. | Республика мәгариф оешмаларында психологик-педагогик юнәлештәге сыйныфлар санын үткән ел белән чагыштырганда 15 процентка арттыру | декабрь | ТР МhФМ |
| 6.4. | Ведомство бүләкләре белән бүләкләнгән педагоглар санын үткән ел белән чагыштырганда 20 процентка арттыру | декабрь | ТР МhФМ |
| 6.5. | Мәгариф оешмаларына яңадан җәлеп ителгән педагогик хезмәткәрләрнең санын үткән ел белән чагыштырганда 10 процентка арттыру | декабрь | ТР МhФМ |

Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:

АПК – «Г.Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе;
КФУ АИ – «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Алабуга институты (филиалы);
ТР МҮИ – «Татарстан Республикасының Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәр белеме бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе;
КФУ – «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе;

ЛБЙ – Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен «Лаеш балалар йорты» дәүләт бюджет учреждениесе;
ТР МһФМ – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;
ТР МБ – Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре;
ЧДПУ – «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе;
ТКБЙ – Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен «Түбән Кама балалар йорты» дәүләт бюджет учреждениесе;
ТР МБ ҖҮО – Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары;
МО – мәгариф оешмалары;
ЮББ МО – югары белем бирү мәгариф оешмалары;
«Татмедиа» РА – Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы;
ММЧ – массакүләм мәгълүмат чаралары.